КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 сентябрь г.Казань № 816

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм аның территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектын алу турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16 200 км – 21 977 км» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII[1] бүлеге, 49 статьясы, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт баш идарәсе) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16 200 км – 21 977 км» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Званка авыл җирлеге, Иске Кощаково авылы, Луговая урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан һәм Э.М.Хәкимов милкендә булган (алга таба – алына торган мөлкәтнең милекчесе) 865 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген 16:33:080201:187 кадастр саны белән һәм аның территориясендә урнашкан 70,1 кв.метр мәйданлы капиталь төзелеш объектын 16:33:080201:362 кадастр саны белән (алга таба – алына торган мөлкәт) дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алу юлы белән алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Званка авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен Татарстанның юл-транспорт баш идарәсенә, алына торган мөлкәтнең милекчесенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрүне;

алына торган мөлкәт өчен каплау күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт баш идарәсе белән берлектә, мөлкәтне Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында килешү (алга таба – мөлкәтне алу турында килешү) әзерләүне һәм аны алына торган мөлкәтнең милекчесенә җибәрүне;

мөлкәтне алу турында килешү төзүне;

алына торган мөлкәт өчен түләүне;

алына торган мөлкәткә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган мөлкәтнең милекчесе тарафыннан законнарда билгеләнгән вакыт эчендә мөлкәтне алу турындагы килешү имза куелып тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин